**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

КАРАР № 36

Иске Каразирек ав. 04 декабрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 23 июнендәге «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы»ның 50-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Иске Каразирек авыл җирлеге Советының 2023 елның 1 мартындагы 2 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.13. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.13. Муниципаль хезмәткәргә сыйныф чины бирү турында карар, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының» 10 маддәсендәге 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә сыйныф чины бирү турында класс чинын бирү вәкаләтле органга яки җирле үзидарә вазыйфаи затына тапшыру көненнән соң бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Иске Каразирек авыл җирлеге
башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.М.Минниярова